**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Березняк авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2023 елның 31 октябре** **№ 8**

**Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Камышлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 14 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Камышлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Камышлы авылы, Ленин урамы, 14 йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 14 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Камышлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Камышлы авылы, Ленин урамы, 14 йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

3. 2023 елның 14 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Камышлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Камышлы авылы, Ленин урамы, 14 йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

4. «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Камышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокլы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Камышлы авылында Сабантуй уздыру урынын төзекләндерү (килешү буенча эш өчен түләү); проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Камышлы авылы скважинасы өчен тирәннән суырту насосы сатып алу;

- Камышлы авылы зиратына кораллар һәм инвентарь сатып алу;

- Камышлы авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, хезмәткәргә хезмәт өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Березняк авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Березняк авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Шәрипов